КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 февраль г.Казань № 89

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2021 ел, 24 декабрь, 1279 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 9 февраль, 104 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге юллардан соң:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 02 55258 09 0000 150 | Халыкка диспансеризация һәм профилактик медицина тикшерүе үткәрү барышында онкологик авыруларны ачыклаган өчен медицина хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» |

түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 02 55854 09 0000 150 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән затларга, шул исәптән яңа короновирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы һәм (яисә) авыруга карата шик белән, территориаль мәҗбүри медицина иминияте программаларын гамәлгә ашыру кысаларында беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүне өстәмә финанс белән тәэмин итүгә тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |
| 395 | 2 02 58501 09 0000 150 | 2021 – 2022 елларда Россия Федерациясе субъектлары һәм Байконур шәһәре территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән затларга, шул исәптән яңа короновирус йогышлы авыруы белән авыручы һәм (яисә) авыруга карата шик белән, территориаль мәҗбүри медицина иминияте программаларын гамәлгә ашыру кысаларында медицина ярдәме күрсәтүне өстәмә финанс белән тәэмин итүгә тапшырыла торган бюджетара трансфертлар»; |

түбәндәге юллардан соң:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 07 10090 09 0000 199 | Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондлары бюджетларына кире кайтарылмый торган һәм акчалата булмаган башка керемнәр» |

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 08 08000 08 0000 150 | Артык түләнгән яки артык түләтелгән салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр суммаларын кире кайтаруны (кертүне), шулай ук үз вакытында әлеге кире кайтаруны гамәлгә ашырмаган өчен процентлар һәм артык түләнгән суммаларга исәпләнгән процентлар суммаларын кире кайтаруны гамәлгә ашыру өчен мәҗбүри медицина иминияте Федераль фонд бюдже-тыннан (мәҗбүри медицина иминияте Федераль фонд бюджетына) күчерү»; |

түбәндәге юллардан соң:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 19 55060 09 0000 150 | Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелгән махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне өстәмә финанс белән тәэмин итү өчен узган еллардагы башка бюджетара трансфертларның калган өлешен мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондлары бюджетларыннан Мәҗбүри медицина иминияте федераль фонды бюджетына кире кайтару» |

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 19 55231 09 0000 150 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыру кысаларында яңа короновирус йогышлы авыруы белән авыручы һәм (яисә) авыруга карата шик белән иминләштерелгән затларга медицина ярдәме күрсәтүне өстәмә финанс белән тәэмин итүгә узган еллардагы калган башка бюджетара трансфертларны кире кайтару». |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген һәм Татарстан Республикасы мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2021 ел, 24 декабрь, 1279 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген һәм Татарстан Республикасы мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм вакытларын раслау хакында» 2022 ел, 4 апрель, 313 нче карарына, 2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Бу карар, 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджетыннан башлап, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин